Мордовия табиблары баш миенә бик катлаулы операция ясаганнар. Аны 4 нче РКХ тобәк кан тамырлары vзәге белгечләре башкарды. Бу хакта vзенен telegram-каналында Мордовия башлыгы Артем Здунов язган.
Житәкче Сергей Николаев пациент-нын авырудан ике елга якын интегvе турында сойләгән. Тикшерvләр нәтижәсендә баш миенен яшәv очен моһим функцияләре очен жаваплы булган урыннары янында шеш табылган. Моннан тыш, шеш аша нервлар vтә, аларга тәэсир итәргә ярамый иде. Операция кирәк булган һәм безнен табибларнын бу вакытта шундый тәжрибәсе бар иде инде.

«Бvгенге кондә Мордовиядә мондый операцияләр бары тик бездә генә башкарыла, – дип билгеләп vтә 1 нче региональ кан тамырлары vзәге житәкчесе Сергей Николаев. - Бу безнен республика очен сирәк очрый торган операция: мондый операция сонгы тапкыр берничә ел элек башкарылган иде. Ләкин быел Зубово-Поляна районыннан безгә йознен ун ягын селкетv турында зарланган пациент килде. Авыру аны ике елга якын борчый, хатын препаратлар кабул итә, әмма дәвалаудан бернинди дә нәтижә булмый. Безнен хастаханәдә кирәкле тикшерv vткәрелде, баш миенен МРТ ясалды. Без операция кирәклегенә инандык».
Авырлыгы шунда ки, шеш аша нервлар vтә: йоз, кvз хәрәкәте (лицевой, глазодвигательный). Бу нервларны имгәтv тупас неврологик катлаулануларга, мәсәлән, йознен кыйшавына китерәчәк. Остәвенә, шеш баш миенен организмнын моһим функцияләре - йорәк-кан тамырлары һәм сулыш vзәкләре очен жаваплы булган урыннары янында урнашкан. Шуна кvрә эш нечкә, ювелир микрохирургия булган.
Операция микроскоп астында, баш соягендәге кечкенә тишек аша башкарылган.
Операция оч сәгатьтән артык барган. Эш нечкә, микроскоп астында кечкенә тишек аша эшләнгән. Барысы да унышлы vткән. Үз - vзен тоюю турында хәзер хатын-кызга яхшырак, табиблар кvзәтvе астында аякка баса.
Билгеләп vтелгәнчә, мондый операцияләрне алга таба да Рес-публика клиник хастаханәсендә vткәрәчәкләр.

Н.ХӘЛИЛ әзерләде